РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

10.09.2026 № 320/Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләр бүлешү турында нигезләмәне раслау хакында» Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 10 мартындагы 76/Бк/к номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33—ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 — ФЗ номерлы Федераль закон (29.12.2025 ред. с изм. 01.01.2026 елдан өстәмәләр белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән (үзгәрешләр белән), Буа муниципаль районында мәгариф системасы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 10 мартындагы 76/Бк/к номерлы карары белән расланган «Буа муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турында Нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Вәкаләтләр бүлешү турында нигезләмәнең 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 1.25 пункт өстәргә:

«1.25. Россия Федерациясендә мәгариф турында «2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 2.1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру».».

1.2. Вәкаләтләр бүлешү турында нигезләмәнең 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 1.26 пункты өстәргә:

«1.26. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 51 статьясындагы 2 өлешендә каралган квалификация таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә

муниципаль мәгариф оешмалары, шул исәптән өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләрен вазыйфаларына билгеләп кую һәм аларның вәкаләтләрен туктату».».

1.3. Вәкаләтләр бүлешү турында нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Муниципаль белем бирү оешмалары, шул исәптән өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләре белән Буа муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфага билгеләп кую (вәкаләтләрен туктату) турындагы карары нигезендә Россия Федерациясе Хезмәт законнарында билгеләнгән тәртиптә хезмәт шартнамәләре төзү, үзгәртү һәм туктату».

1.4. Вәкаләтләр бүлешү турында нигезләмәнең 2 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 2.26 пункт өстәргә:

«2.26. Өстәмә белем бирү оешмаларын да кертеп, муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләрен вазыйфага билгеләү һәм вәкаләтләрен туктату мәсьәләләре буенча материаллар әзерләү һәм Буа муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдимнәр кертү».

1.5. Вәкаләтләр бүлешү турында нигезләмәнең 2 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 2.27 пункт өстәргә:

«2.27. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчесе һәм җитәкчеләре вазыйфасына кандидатларны аттестацияләүне оештыру һәм үткәрү, аттестация комиссиясе составын төзү һәм аның эшен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Буа муниципаль районы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә тәэмин итү».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары — «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Н.А.Македонскаяга йөкләргә.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе Л. Р. Шакирҗанов